Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

17 ноябрь, 2022 ел № 14

Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 8 октябрендәге 137 номерлы карарларына үзгәрешләр белән), кергән гаризалар нигезендә карар бирә:

1. Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы адресы буенча кадастр номеры 16:33:121413:967, мәйданы 6 026 кв.м. булган җир участогына - «2.5 Урта катлы торак төзелеше» азкатлы торак төзелеше зонасында (Ж2),

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы адресы буенча кадастр номеры 16:33:121413:969, мәйданы 4 655 кв.м. булган җир участогына - «2.5 Урта катлы торак төзелеше» азкатлы торак төзелеше зонасында (Ж2),

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны – 2022 елның 25 ноябрена 13.00 сәгатьтә Питрәч муниципаль районы Советының кече залында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча: 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет ур., 18 йорт;

2.3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы адресы буенча: 422770, Татарстан

Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет ур., 18 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр) авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм проектлар буенча кисәтүләр тапшырылырга мөмкин;

2.4. Питрәч авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проектның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен, түбәндәге адрес буенча оештырырга: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты - 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. 2022 елның 3 декабренә кадәр «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов